**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3927**
**15.05.2023**

Башкарма комитетның 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 15 пунктчасы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 17 апрелендәге 2289 номерлы, 2021 елның 29 гыйнварындагы 543 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 пунктта:

- 9, 10 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) медиаэкран, суперсайт, пилларс, реклама стеласы, пилон фундаментына кадәр 5 метрдан ким арада;»;

10) стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру җәяүлеләр зонасы киңлеген 3 метрдан ким кечерәйткән очракта, җәяүлеләр зоналарында;»;

2) 30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. Хуҗалык итүче субъект гамәлдәге Схемадагы яки компенсация урыннары исемлегендәге буш урыннар арасыннан компенсация урыны сайлаган очракта, Башкарма комитет исеменнән Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе компенсация урыны сайлау турындагы хәбәрне алганнан соң 3 эш көне эчендә, Хуҗалык итүче субъектка урнаштыру буенча элек төзелгән Шартнамәне өзү һәм, Хуҗалык итүче субъект тарафыннан сайланган урнаштыру урынын исәпкә алып, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга

Шартнамә төзү өчен Башкарма комитетка килергә кирәклеге турында белдерү кәгазе җибәрә. Хуҗалык итүче субъект яки аның вәкиле, әлеге белдерү кәгазен алганнан соң 10 эш көне эчендә, урнаштыру буенча элек төзелгән Шартнамәне өзү һәм, Хуҗалык итүче субъект тарафыннан сайланган урнаштыру урынын исәпкә алып, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга Шартнамә төзү өчен вәкаләтле органга килергә тиеш.

Хуҗалык итүче субъект Башкарма комитет тәкъдим иткән компенсация урыннарыннан баш тарткан очракта, Хуҗалык итүче субъект стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен компенсация урыны бирүгә хокукын югалта.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов